# ТАТАР ФОЛЬКЛОРЫ ТЕЛЕ

# ЯЗЫК ТАТАРСКОГО ФОЛЬКЛОРА

АКАДЕМИЯ НАУК РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ИНСТИТУТ ЯЗЫКА ЛИТЕРАТУРЫ И ИСКУССТВА
им. Г. ИБРАГИМОВА

**К.Р. Галиуллин**

# ЯЗЫК ТАТАРСКОГО ФОЛЬКЛОРА

## ПОСЛОВИЦЫ, КРЫЛАТЫЕ ВЫРАЖЕНИЯ, ПРИСЛОВЬЯ И ПОГОВОРКИ

СЛОВАРЬ

Казань
2018

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ исем.
ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

**К.Р. Галиуллин**

# ТАТАР ФОЛЬКЛОРЫ ТЕЛЕ

## МӘКАЛЬЛӘР, КАНАТЛЫ ӘЙТЕЛМӘЛӘР, ҖОР СҮЗЛӘР ҺӘМ ӘЙТЕМНӘР

СҮЗЛЕК

Казан
2018

**УДК 811.512.145:398.9:81.374**
**ББК 81.632.3-4:82.3(2=632.3)-4**
**Г15**

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*Гыйльми советы карарына нигезләнеп басыла*

«2014–2020 елларда Татарстан Республикасы дәүләт телләре
һәм Татарстан Республикасындагы башка телләрне саклау,
өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында нәшер ителә

**Фәнни редактор**
филология фәннәре докторы, профессор **К.М. Миңнуллин**

**Рецензентлар:**
ТӘһСИ ның лексикография бүлеге мөдире, филология фәннәре кандидаты
**Р.Т. Сәфәров**,
ТӘһСИ ның халык иҗаты бүлеге мөдире, филология фәннәре кандидаты
**И.И. Ямалтдинов**

**Галиуллин К.Р.**
**Г15** Татар фольклоры теле: мәкальләр, канатлы әйтелмәләр, җор сүзләр һәм әйтемнәр: сүзлек = Язык татарского фольклора: пословицы, крылатые выражения, присловья и поговорки: словарь / К.Р. Галиуллин; фәнни ред. К.М. Миңнуллин. – Казан: ТӘһСИ, 2018. – 588 б.
ISBN 978-5-93091-281-4

Әлеге хезмәт – татар паремияләренең дүрт төре (мәкальләр, канатлы әйтелмәләр, әйтемнәр, җор сүзләр) материалларын системалаштырып тасвирлаучы белешмәлек, хәзерге вакытта төзелеп килә торган татар паремияләре теле белешмәлекләре комплексының мөһим компонентларыннан берсе. Басманың төп өлешен конкорданс, сүз формаларының кире һәм ешлык сүзлекләре тәшкил итә.

Белешмәлек филологларга, сүзлекләр һәм уку әсбаплары төзүчеләргә, укытучыларга, студентларга, укучыларга, шулай ук татар халкының авыз иҗаты, аның теле белән кызыксынучыларга тәкъдим ителә.

Данный труд представляет собой справочник, содержащий систематизированное описание материалов четырех видов татарских паремий – пословиц, крылатых выражений, поговорок и присловий, является одним из основных компонентов создаваемого в настоящее время комплекса справочников, посвященных языку татарских паремий. Основная часть издания содержит конкорданс, обратный и частотный словари словоформ.

Справочник предназначен филологам, составителям словарей и учебных пособий, преподавателям, студентам и учащимся, а также всем интересующимся устным творчеством татарского народа, его языком.

**УДК 811.512.145:398.9:81.374**
**ББК 81.632.3-4:82.3(2=632.3)-4**

**ISBN 978-5-93091-281-4**

© Галиуллин К.Р., 2018
© Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият
һәм сәнгать институты, 2018

# 1. КЕРЕШ ○ ВВЕДЕНИЕ

## 1.1.1. СҮЗ БАШЫ

Лингвофольклористика – хәзерге филология фәненең актив үсештәге өлкәләреннән берсе. Бу өлкәдәге тикшеренүләр арасыннан шактый зур урынны паремияләр (мәкаль, әйтем һәм башка кече фольклор жанрлары) теленә, аның төрле аспектларына багышланган хезмәтләр алып тора (к., мәсәлән, татар тел белемендә [Нәбиуллина 2003; Мөгътәсимова 2005; Федорова, 2004; Юсупова һ. б. 2010]).

Хәзерге вакытта фольклор теле сүзлекләрен төзү перспективалы юнәлешләрдән санала [Бобунова 2004].

Әлеге китап – татар фольклор лингвографиясендә[1] халык авыз иҗаты әсәрләре теленең сүзлеген тасвирлауның беренче тәҗрибәсе. Ул – төзелеп килгән татар паремияләре теленә багышланган белешмәлекләр комплексының төп компонентларыннан берсе.

Белешмәлек татар паремияләренең төрле чыганаклардан алынган материалларны (шулар арасында: [Исәнбәт 2010, ТХИ 1987 һ. б.]) туплаган компьютер фонды нигезендә төзелде. Әлеге белешмәлекнең электрон текстотекасы нигезен татар фольклорының 12 томлык җыелма басмасы, паремияләргә багышланган том [ТХИ 1987] материаллары тәшкил итә. Текстотекага 174 тематик төркем составына һәм афористик фольклор әсәрләренең дүрт төренә – мәкальләр һәм канатлы әйтелмәләр, әйтемнәр һәм җор сүзләргә, караган 17 424 паремия (шул исәптән 335 вариант) керде.

Белешмәлекнең төп өлешен конкорданс, кире (инверсион) һәм ешлык сүзлекләре тәшкил итә.

Конкорданс – паремия рәвешендәге мисаллар белән китерелгән сүз формаларының алфавит күрсәткече. Конкорданс төрле типтагы текст материалларын тасвирлаган сүзлекләр арасында үзенә аерым урын били, Көнбатыш Европа һәм Төньяк Америка илләренең күбесендә ул гаять популяр [Карпова 1984]. Рус телендәге текстларның да конкорданслары шактый [Русская 2003; Шестакова 2011]. Андый белешмәлекләр

---

[1] Лингвография – тел гыйлеменең дисциплинаара өлкәсе, тел белешмәлекләре, сүзлекләр төзүнең теориясе һәм практикасы (лингвография турында к. [Компьютерная 1995: 5–9]); аның бүлекчәләре – лексикография, фразеография, морфемография, паремиография һ. б.

татар лингвографиясендә дә барлыкка килде (к., мәсәлән, [Галиуллин, Кәримуллина, Минһаҗева 2006, 2009]). Шулай ук конкордanslar төрле фольклор жанрлары (шул исәптән мәкаль һәм әйтемнәр) телен тасвирлаганда да файдаланыла [Бобунова 2007; Галиуллин, Мартьянов 2006].

Кире сүзлектә инверсион алфавит тәртибендә урнашкан сүз формалары бирелә (статистик мәгълүматлар белән).

Ешлык сүзлегендә татар паремияләрендә 10 тапкыр һәм аннан да артыграк очраган сүз формалары китерелә.

Әлеге сүзлекләр татар паремияләренең академик басмасына [ТХИ 1987] белешмәлек-күрсәткечләр булып хезмәт итә алалар.

Автор, фәнни тикшеренүләргә дә, дидактик филологиягә дә материал бирүче әлеге белешмәлек татар фольклоры телен алга таба тагын да тирәнтенрәк өйрәнергә этәргеч бирер, дип өметләнә. Сүзлек паремияләр материалларының системалаштырылган җыентыгы сыйфатында филологларга, сүзлекләр һәм уку әсбаплары төзүчеләргә, укытучыларга, шулай ук татар халкының авыз иҗаты, аның теле белән кызыксынучыларга файдалы булачак.

Автор фонд һәм сүзлек концепциясен тикшерүдә катнашкан филолог-коллегаларга, барлык белгечләргә ярдәмнәре һәм теләктәшлекләре өчен рәхмәтле.

Материал туплауда һәм татар фольклоры фондын булдыруның төрле этапларында катнашкан Г.Д. Ибраһимова, Р.Н. Кәримуллина, Г.Н. Кәримуллина, А.Н. Кәримуллинага автор тирән рәхмәтен белдерә.

Фәнни редактор К.М. Миңнуллинга, рецензентлар Р.Т. Сәфәров һәм И.И. Ямалтдиновка аерым рәхмәт.

Татар паремияләре теле сүзлегенең фонды һәм башка компонентлары өстендә эш дәвам итә, аерым алганда, сүзлекнең электрон версиясе төзелә.

Автор фондның һәм сүзлекнең мәгълүмати мөмкинлекләрен арттыра һәм баета алырдай теләк-тәкъдимнәр көтеп кала. Алар комплекслы белешмәлекнең алдагы компонентларын эшләгәндә исәпкә алыначак.

**E-mail:** galiullin.kamil@mail.ru

## 1.1.2. ПРЕДИСЛОВИЕ

Лингвофольклористика – одна из активно развивающихся областей современной филологической науки. Значительное место среди исследований в этой области занимают работы, посвященные языку паремий (пословиц, поговорок и ряда других малых фольклорных жанров), различным его аспектам (см., например, в татарском языкознании [Нәбиуллина 2003; Мөгътәсимова 2005; Фёдорова 2004; Юсупова и др. 2010]).

В настоящее время к числу перспективных относится направление, связанное с созданием словарей языка фольклора [Бобунова 2004].

Данная книга представляет собой первый в татарской фольклорной лингвографии[1] опыт словарного описания языка произведений устного народного творчества. Она является одним из основных компонентов создаваемого комплекса справочников, посвященных языку татарских паремий.

Справочник составлен на основе компьютерного фонда татарских паремий, включающего материалы различных источников (среди которых: [Исәнбәт 2010, ТХИ 1987 и др.]). В основу электронной текстотеки данного справочника легли материалы 12-томного собрания татарского фольклора, тома, посвященного паремиям [ТХИ 1987]. В текстотеку вошли 17 424 паремии (в том числе 335 вариантов), входящие в 174 тематические группы и относящиеся к четырем видам афористических фольклорных произведений: пословицы и крылатые выражения, поговорки и присловья.

Основная часть справочника содержит конкорданс, обратный (инверсионный) и частотный словари.

Конкорданс – алфавитный словоформоуказатель с примерами-паремиями. Конкорданс занимает особое место среди словарей, описывающих материалы текстов различного типа, и пользуется большой популярностью в национальных лингвографиях многих стран Западной Европы и Северной Америки [Карпова 1984]. Немало конкордансов и к русскоязычным текстам [Русская 2003; Шестакова 2011]. Появились эти справочники и в татарской лингвографии (см., например, [Галиуллин, Кәримуллина, Минһаҗева 2006, 2009]). Используются конкордансы также при описании языка разных жанров

[1] Лингвография – междисциплинарная область языкознания, теория и практика создания языковых справочников, словарей (о лингвографии см.: [Компьютерная 1995: 5–9]); ее подразделами являются лексикография, фразеография, морфемография, паремиография и др.

фольклора, включая пословицы и поговорки [Бобунова 2007; Галиуллин, Мартьянов 2006].

В обратном словаре словоформы расположены в инверсионном алфавитном порядке (со статистическими данными).

Частотный словарь включает в себя словоформы, которые встречаются в татарских паремиях 10 и более раз.

Данные словари могут использоваться как справочники-указатели к академическому изданию татарских паремий [ТХИ 1987].

Справочник содержит материал для научных исследований и для дидактической филологии, автор надеется, что он будет источником, стимулирующим дальнейшее углублённое изучение языка татарского фольклора. В качестве систематизированного собрания материалов паремий он будет полезен филологам, составителям словарей и учебных пособий, преподавателям, также всем интересующимся устным народным творчеством татарского народа, его языком.

Автор признателен коллегам-филологам, всем специалистам, принимавшим участие в обсуждении концепции фонда и словаря, за помощь и поддержку.

В сборе материала и формировании фонда татарского фольклора на разных этапах участвовали Г.Д. Ибрагимова, Р.Н. Каримуллина, Г.Н. Каримуллина, А.Н. Каримуллина, которым автор выражает свою глубокую благодарность.

Особая признательность научному редактору К.М. Миннуллину, рецензентам Р.Т. Сафарову и И.И. Ямалтдинову.

Работа над фондом и другими компонентами словаря языка татарских паремий продолжается, в частности, создается электронная версия справочника.

Автор с благодарностью примет пожелания, направленные на повышение информационного потенциала фонда и словаря, которые будут учтены в работе над последующими компонентами комплексного справочника.

**E-mail:** galiullin.kamil@mail.ru

## 1.2.1. БЕЛЕШМӘЛЕКНЕҢ ТӨЗЕЛЕШЕ

Белешмәлек кереш, сүзлекләр бүлеге һәм кушымтадан гыйбарәт.

### КЕРЕШ

Керешкә (⇨ 1) ике бүлекчә керә:

● «Сүз башы» (татар телендә ⇨ 1.1.1; рус телендә ⇨ 1.1.2); биредә белешмәлеккә гомуми характеристика бирелә;

● «Белешмәлекнең төзелеше» (татар телендә ⇨ 1.2.1; рус телендә ⇨ 1.2.2); биредә белешмәлекнең бүлекләре һәм бүлекчәләре тасвирлана.

### СҮЗЛЕКЛӘР БҮЛЕГЕ

Сүзлекләр бүлегенә (⇨ 2) өч бүлекчә керә:

● «Конкорданс»;
● «Кире сүзлек»;
● «Ешлык сүзлеге».

### **Конкорданс**

Конкорданс (⇨ 2.1) – татар паремияләре рәвешендәге мисаллар белән китерелгән сүз формалары күрсәткече; ул мәкальләр, канатлы әйтелмәләр, әйтемнәр һәм җор сүзләрдә теркәлгән 19 269 сүз формасын тасвирлый. Аның мәкаләләрендә шулай ук сүз формаларының ешлыгы күрсәтелә.

Сүзлек мәкаләләре конкордансга алфавит тәртибендә урнаша.

Конкордансга ике төрдәге мәкаләләр бирелә:

a) төп мәкаләләр;
b) башка сүзгә җибәрүче мәкаләләр (сылтамалар).

#### Төп мәкаләләр

Төп мәкаләләрдә биш зона бар:

1) баш берәмлек;
2) баш берәмлек ешлыгы;
3) баш берәмлек кулланылган паремия;
4) китерелгән паремиянең номеры;
5) баш берәмлек кулланылган башка паремияләрнең номерлары.

Мәсәлән:

**АВЫЛДАШ** (5) ■ Авылдаш атлар ерактан кешнәшер, якыннан тибешер ○ 2448 ● 6959; 11739; 14165 (2)

1) Баш берәмлек.

Баш берәмлек – паремияләрдә теркәлгән сүз формасы ул; мәсәлән:

**ЮЛБАРЫС** (5) <...>

Аерым баш берәмлекләр итеп сүзләрнең төрле вариантлары китерелә (к., мәсәлән, *аршин – аршын* һ. б.).

Бу белешмәлектә сүзләрнең һәм сүз формаларының омонимнары аерылмый (к., мәсәлән, *ал, бар* мәкаләләре һ. б.).

Омонимик сүзләрне һәм сүз формаларын аерырга түбәндәге контекстлар ярдәм итә:

a) конкордансга бирелгән контекстлар; сүз формаларының яртысыннан артыграгы (55,3%) өчен конкордансга аларның татар паремияләрендә куллануның бөтен мисаллары китерелә;

b) шулай ук [ТХИ 1987] дә китерелгән контекстлар; әлеге контекстлар белән оператив танышуга конкорданс мәкальләрендә күрсәтелгән паремия номерлары булышлык итә.

Контекстлар тулысы белән белешмәлекнең электрон версиясендә урын алачак.

2) Баш берәмлек ешлыгы.

Баш берәмлектән соң (түгәрәк җәяләрдә) абсолют ешлык – сүзнең кулланылыш саны (тексттагы сүзләр саны) турында мәгълүматлар китерелә; мәсәлән:

**КАТЫК** (16) <…>

Паремия вариантларында кулланылыш саны турындагы мәгълүматлар вертикаль сызыктан ( | ) соң китерелә; мәсәлән:

**БӘК** (2 | 3) <…>
**ТУЕЗ** ( | 1) <…>

3) Баш берәмлекнең кулланылыш мисалы.

Кулланылыш мисалы – шушы сүз формасы булган паремия; мисал кара квадраттан (■) соң китерелә; мәсәлән:

**ДОРФА** (2) ■ Дорфа сүздән дорфа эш яхшы ○ 15831 (2)

4) Китерелгән паремия номеры.

Паремия номерлары татар фольклорының академик басмасындагы [ТХИ 1987] номерларга тәңгәл килә.

Паремия номеры ак түгәрәктән (○) соң бирелә; мәсәлән:

**ШАУЛЫ** (1) ■ Шаулы яңгыр тиз үтәр ○ 1149

Паремия вариантының санлы билгесенә әлеге вариантның номеры өстәлә (ике ноктадан соң); мәсәлән:

**АЗЫКСЫЗ** (1 | 1) ■ Азыклы ат армас, азыксыз ат бармас ○ 2451:1 ● 8847

Әгәр сүз формасы паремиядә яки аның вариантында ике тапкыр һәм аннан да ешрак очраса, паремия номерыннан соң түгәрәк җәяләрдә әлеге сүз формасының кулланылыш саны күрсәтелә; мәсәлән:

**КОРАЛАЙ** (3) ■ Коралай килми – кыш җитми, коралай китми – яз җитми ○ 859 (2) ● 2226

5) Баш берәмлек кулланылган башка паремияләрнең номерлары.

Башка паремияләрнең номерлары кара түгәрәктән (●) соң бирелә; паремия номерлары арасында – нокталы өтер, ә вариант номерлары арасында өтер куела; мәсәлән:

**ЮГАРЫГА** (8 | 2) ■ Йөзсәң, югарыга йөз ○ 391 ● 695, :1, :2; 696; 709–712; 11311

Башка сүзгә җибәрә торган мәкаләләр (сылтамалар)

Конкорданста икенче тамыр компонентларыннан парлы (дефислы) сүзләргә җибәрә торган мәкаләләр бар; мәсәлән:

**әни → әти-әни**
**көчек → мәче-көчек**

## Кире сүзлек

Кире сүзлектә (⇨ 2.2) ахыргы хәрефләре буенча алфавит тәртибендә урнашкан 19 269 сүз формасы исемлеге урын ала; мәсәлән:

(1) ▪ А
$^{4}$1/5°(5) ▪ КАБА
(1) ▪ САБА
$^{4}$2/3°(2) ▪ САВЫТ-САБА
$^{4}$1/55°(55) ▪ ТАБА
<...>

(1) ▪ ЯМАНЧЫЛЫК
(1) ▪ ТАРЧЫЛЫК
(1) ▪ БАГУЧЫЛЫК
$^{4}$18/92°(44) ▪ ЯХШЫЛЫК
$^{4}$1/3$^{3}$153/672°(3) ▪ КЫЮЛЫК
<...>

Кечкенә кара квадраттан сулда статистик мәгълүматлар китерелә:

а) түгәрәк җәяләрдә – сүз формасының ешлыгы;

b-e) өскә күтәрелгән $^{4,\ 3,\ 2,\ 1}$ саннарыннан соң – ахырлары әлеге сүз формасының 4-, 3-, 2-, 1-хәрефле ахырына охшаш булган барлык сүз формаларының саны, шулай ук (кыек сузыктан соң) – әлеге сүз формаларының кулланылыш саны; мәсәлән:

$^{4}$1/11$^{3}$1/11$^{2}$3/99$^{1}$54/381°(11) ▪ ДӘРЬЯ
b c d e a

## Ешлык сүзлеге

Ешлык сүзлегендә (⇨ 2.3) татар паремияләрендә 10 тапкыр һәм аннан да ешрак очрый торган 1745 сүз формасы бирелә.

Сүз формалары ешлыклары кимү тәртибендә [1259 (1230 | 29) дан 10 га кадәр] урнаша. Тиң ешлыклы сүзләр алфавит тәртибендә бирелә.

Түгәрәк җәяләр эчендә сүз формаларының абсолют ешлыгы күрсәтелә. Башта – татар паремияләренең төп өлешендәге сүз формаларының саны, аннары (вертикаль сызыктан соң) вариантлардагы саны турында мәгълүматлар китерелә; мәсәлән:

ДА (1230 | 29)
БЕЛӘН (1197 | 20)
БЕР (1100 | 21)
ДӘ (893 | 19)
ЮК (755 | 8)
<...>

ЙОДРЫК (12)
ЙӨРӘГЕ (12)
КАЕНАНА (12)
КАЙТМАС (12)
КАЛҖА (10 | 2)
<...>

1 дән 9 га кадәр ешлыктагы баш берәмлекләр конкорданста (⇨ 2.1) тасвирлана.

КУШЫМТА

Кушымтага (⇨ 3) өч бүлекчә керә:

● «Шартлы билгеләмәләр һәм кыскартылмалар» (татар телендә ⇨ 3.1.1; рус телендә ⇨ 3.1.2);

● «Әдәбият» (⇨ 3.2);

● «Татар паремияләре: тематик классификация планы» (татар телендә ⇨ 3.3.1; рус телендә ⇨ 3.3.2). План 19 тематик бүлек һәм 174 тематик төркемнән тора һәм түбәндәге мәгълүматны алу мөмкинлеген бирә:

a) татар паремияләре кергән тематик бүлек һәм төркемнәрнең составы нинди;

b) теге яки бу паремияләр нинди тематик бүлек һәм төркемнәргә керә;

c) теге яки бу паремия паремияләрнең кайсы төренә (мәкальләргә һәм канатлы әйтелмәләргә яисә әйтемнәр һәм җор сүзләргә) карый.

## 1.2.2. СТРУКТУРА СПРАВОЧНИКА

Справочник состоит из введения, словарной части и приложения.

### ВВЕДЕНИЕ

Введение (⇨ 1) включает два подраздела:

● «Предисловие» (на татарском языке ⇨ 1.1.1; на русском языке ⇨ 1.1.2); здесь дана общая характеристика справочника;

● «Структура справочника» (на татарском языке ⇨ 1.2.1; на русском языке ⇨ 1.2.2); здесь описаны разделы и подразделы справочника.

### СЛОВАРНАЯ ЧАСТЬ

Словарная часть (⇨ 2) включает три подраздела:

● «Конкорданс»;

● «Обратный словарь»;

● «Частотный словарь».

#### Конкорданс

Конкорданс (⇨ 2.1) представляет собой словоформоуказатель с примерами в виде татарских паремий и описывает 19 269 словоформ, зафиксированных в пословицах, крылатых выражениях, поговорках и присловьях. В статьях конкорданса также даны сведения о частоте словоформ.

Словарные статьи расположены в конкордансе в алфавитном порядке.

В конкордансе представлены статьи двух типов:

a) основные статьи;

b) отсылочные статьи (отсылки).

##### Основные статьи

Основные статьи имеют пять зон:

1) заголовочная единица;

2) частота заголовочной единицы;

3) паремия, в которой употребляется заголовочная единица;

4) номер приведённой паремии;

5) номера других паремий, в которых употребляется заголовочная единица.

Например:

**АВЫЛДАШ** (5) ■ Авылдаш атлар ерактан кешнәшер, якыннан тибешер ○ 2448 ● 6959; 11739; 14165 (2)

1) Заголовочная единица.

Заголовочная единица – это словоформа, зафиксированная в паремиях; например:

**ЮЛБАРЫС** (5) <...>

Отдельными заголовочными единицами приводятся различные варианты слов (см., например, *аршин – аршын* и др.).

Омонимы слов и форм слов в данном справочнике не разграничиваются (см., например, статьи *ал, бар* и др.).

Разграничить омонимичные слова и формы слов позволяют контексты:

a) представленные в конкордансе; для более чем половины словоформ (55,3 %) в конкордансе приведены все примеры употребления их в татарских паремиях;

b) а также представленные в [ТХИ 1987], оперативному доступу к этим контекстам помогают номера паремий, указанные в статьях конкорданса.

Вся совокупность контекстов будет приведена в электронной версии справочника.

2) Частота заголовочной единицы.

За заголовочной единицей (в круглых скобках) приводятся сведения об абсолютной частоте – количестве словоупотреблений (текстовых слов); например:

**КАТЫК** (16) <…>

Сведения о количестве употреблений в вариантах паремий приводятся после вертикальной линии ( | ); например:

**БӘК** (2 | 3) <…>
**ТУЕЗ** ( | 1) <…>

3) Пример употребления заголовочной единицы.

Пример употребления – паремия, в которой представлена данная словоформа; пример приводится за черным квадратом (■); например:

**ДОРФА** (2) ■ Дорфа сүздән дорфа эш яхшы ○ 15831 (2)

4) Номер приведённой паремии.

Номера паремий соответствуют нумерации, представленной в академическом издании татарского фольклора [ТХИ 1987].

Номер паремии приводится за светлым кружком (○); например:

**ШАУЛЫ** (1) ■ Шаулы яңгыр тиз үтәр ○ 1149

У варианта паремии цифровое обозначение дополняется (после двоеточия) порядковым номером этого варианта; например:

**АЗЫКСЫЗ** (1 | 1) ■ Азыклы ат армас, азыксыз ат бармас ○ 2451:1 ● 8847

Если словоформа встречается в паремии или в варианте паремии два раза и более, то после номера паремии в круглых скобках указывается количество употреблений данной словоформы, например:

**КОРАЛАЙ** (3) ■ Коралай килми – кыш җитми, коралай китми – яз җитми ○ 859 (2) ● 2226

5) Номера других паремий, в которых употребляется заголовочная единица.

Номера других паремии приводятся за тёмным кружком (●); между номерами паремий стоит точка с запятой, а между номерами вариантов – запятая; например:

**ЮГАРЫГА** (8 | 2) ■ Йөзсәң, югарыга йөз ○ 391 ● 695, :1, :2; 696; 709–712; 11311

Отсылочные статьи (отсылки)

В конкордансе содержатся отсылочные статьи к сложным (дефисным) словам от их вторых корневых компонентов; например:

**әни → эти-әни**
**көчек → мәче-көчек**

## Обратный словарь

Обратный словарь (⇨ 2.2) содержит 19 269 словоформ, расположенных в обратном алфавитном порядке с учётом конечных букв слова, например:

| | |
|---|---|
| (1) ▪ А | (1) ▪ ЯМАНЧЫЛЫК |
| $^{4}$1/5°(5) ▪ КАБА | (1) ▪ ТАРЧЫЛЫК |
| (1) ▪ САБА | (1) ▪ БАГУЧЫЛЫК |
| $^{4}$2/3°(2) ▪ САВЫТ-САБА | $^{4}$18/92°(44) ▪ ЯХШЫЛЫК |
| $^{4}$1/55°(55) ▪ ТАБА | $^{4}$1/3$^{3}$153/672°(3) ▪ КЫЮЛЫК |
| <...> | <...> |

Слева от маленького чёрного квадрата приведены статистические сведения:

а) в круглых скобках – частота словоформы;

b-e) после выносных цифр $^{4,3,2,1}$ – количество всех словоформ, имеющих 4-, 3-, 2-, 1-буквенную финаль, сходную с финалью данной словоформы, а также (после косой линии) – количество употреблений этих словоформ; например:

$^{4}$1/11$^{3}$1/11$^{2}$3/99$^{1}$54/381°(11) ▪ ДӘРЬЯ
b c d e a

## Частотный словарь

Частотный словарь (⇨ 2.3) включает 1745 словоформ, которые встречаются в татарских паремиях 10 раз и более.

Словоформы расположены в порядке убывания частоты [от 1259 (1230 | 29) до 10]. Слова с одинаковой частотой располагаются в алфавитном порядке.

В круглых скобках указана абсолютная частота словоформ. Сначала приведены сведения о количестве текстовых словоформ в основной части татарских паремий, затем (после вертикальной линии) – в вариантах; например:

ДА (1230 | 29)
БЕЛӘН (1197 | 20)
БЕР (1100 | 21)
ДӘ (893 | 19)
ЮК (755 | 8)
<...>

ЙОДРЫК (12)
ЙӨРӘГЕ (12)
КАЕНАНА (12)
КАЙТМАС (12)
КАЛҖА (10 | 2)
<...>

Заголовочные единицы с частотой от 1 до 9 описаны в конкордансе (⇨ 2.1).

## ПРИЛОЖЕНИЕ

Приложение (⇨ 3) включает в себя три подраздела:

● «Условные обозначения и сокращения» (на татарском языке ⇨ 3.1.1; на русском языке ⇨ 3.1.2);

● «Литература» (⇨ 3.2);

● «Татарские паремии: план тематической классификации» (на татарском языке ⇨ 3.3.1; на русском языке ⇨ 3.3.2). План включает 19 тематических разделов и 174 тематические группы и позволяет получить следующую информацию:

a) каков состав тематических разделов и групп, к которым отнесены татарские паремии;

b) к каким тематическим разделам и группам относятся те или иные паремии;

c) к какому виду паремий (к пословицам и крылатым выражениям или к поговоркам и присловьям) относится та или иная паремия.